СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.05.2025№ 58/5

На №__________от______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, муниципаль округларның генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары буенча һәм җирлекләрнең генераль планнарына, муниципаль округларның генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яки халык тыңлаулары (әлеге статьяда алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яки халык тыңлаулары) муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 3_1 - 3_3 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында

(https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров